# "ӘКИЯТЛӘР"

# ТЕМАСЫНА ИҖАДИ ЭШ

# Иҗади эшнең актуальлеге:

**Максатлар:**

1. Татар халык авыз иҗаты буларак әкият турында белгәннәрне искә төшерү, әкиятләргә халык акылы, тапкырлыгы, зирәклеге, батырлыгы салынуын аңлату, шул турыда уйларга өйрәтү;
2. Әкиятләрне төрләре буенча бер-берсеннән аера белүгә ирешү;
3. Әкият геройлары үрнәгендә укучыларга хезмәт тәрбиясе бирү, ата-ананы, өлкәннәрне ярату, хөрмәт итү хисләре булдыру.

**Предметара бәйләнеш:** татар теле, әйләнә-тирә дөнья һәм әдәбият

**Эш төрләре (алымнар):** сорау-җавап, уен, карточкалар белән эш, проблемалы сорау.

## Эшнең максаты:

**1.** Сөйләм осталыгы һәм күнекмәләре формалаштыру.
**2.** Балаларда ана телен өйрәнүгә кызыксыну, омтылыш, эзләнүгә теләк уяту.
**3.** Татар теленә карата хөрмәт һәм ихтирам тәрбияләү, телнең чисталыгын, дөреслеген саклап, халыкның рухи мирасын өйрәнүгә кызыксыну уяту.

## Бурычлар:

Тәрбияви: Әкиятләрне кызыксынып уку.
Үстерешле: Сөйләм телен үстерү.
Өйрәтү: Укыган әкиятләрне матур, сәнгатьле итеп сөйли белү

Әкиятләр - халык авыз иҗатының бик борынгы төре. Ул, гасырлар буена югалмыйча, телдән телгә күчеп килгән.

Халык әкиятләре тупланган китапны ачкач, без анда әкият авторының исем-фамилиясен күрмибез. Чөнки бу әкиятләрнең авторы билгесез. Авторы билгеле булган әкиятләрне «әдәби әкиятләр» яки «автор әкиятләре» дип йөртәләр.
















# ӘКИЯТЛӘР

- хайваннар турындагы әкиятләр
- тылсымлы әкиятләр
- тормыш- көнкүреш әкиятләре

## Укучыларны төркемнәргә бүлү.

**Бирелгән материаллар арасыннар туры килгәннәрен сайлап эшләү һәм яклау.**

**Беренче төркем** – *биремнәрне эшләү.*

**Икенче төркем** – *ошаган әкияткә, рәсемнәр белән бизәп, китапчыклар, буклетлар яки плакатлар ясау.*

**Өченче төркем** - *яңа әкият язып карау.*

1. Бу рәсем кайсы әкияттән? Ничек уйлыйсың, бу нинди әкиятләр (хайваннар турындамы, көнкүреш әкиятеме, тылсымлы әкиятме?)








## 2. Бу әкиятләр арасында аерма бармы? Нинди әкиятләрне халык әкиятләре һәм автор әкиятләре дип атыйбыз?













# 3. Бу өзек кайсы әкияттән алынган?

1) Яп-ялангач, нәп-нәзек, ләкин кеше төсле үзе;
Урта бармак буйлыгы бар маңгаенда мөгезе.

2) Акбай — кызга, кыз — әбигә, әби — бабайга, бабай шалканга тотынды. Әй тарталар, әй тарталар — шалкан һаман чыкмый, селкенми дә.

3) Бер Соры куянның үзе төсле зур колаклы, бик иркә, бик кадерле бер кызы булган. Көннәрдән беркөнне Куян иркә кызына өр-яңа киез итекләр алып кайтып биргән.

4) Бер әбинең ике әтәче булган. Бу әтәчләрнең берсе ак, берсе кара икән.

5) Җәй көне: эссе һавада мин суда коенам, йөзәм,
Чәчрәтәм, уйныйм, чумам, башым белән суны сөзәм.

6) Йомры икмәк һаман тәгәрәвен белгән. Менә бервакыт аның каршысына бер бүре килеп чыккан.

# 4. Бу герой кайсы әкияттән?



1) Малай алтын тарак урлап алып кайта.
2) Кыз үрмәкүчкә әверелә.
3) Тычкан килмәсә шалканны тартып алып булмый иде.
4) Былтыр бүрәнә ярыгына кемнең бармагын кыса?







# 5. Әйберләр кайсы әкияттән? Исемнәрен ата.









## Көтелгән нәтиҗәләр:

1. Әкиятләрне кызыксынып укый башлау.

2. Сөйләм байлыгы арта, сөйләм теле үсә.

3. Әкиятләргә карата иҗади сәләт (китапчык,  иллюстрация, аппликация  ясау, әк иятләр язу, әвәләү)  үстерелә.